**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар**
**(муниципаль этап, 2021-2022 уку елы)**
**7нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 150 минут**
**Гомуми балл – 45**

**1. Әдәбият теориясе.**

1. Мәкаль һәм әйтемгә хас үзенчәлекләрне аңлатыгыз (3б.+3б., барлыгы 6 балл).

**Җавап:** Көнкүрештә күп сыналган тәҗрибә һәм дәлил урынында әйтеп йөртелә торган, кыска, ләкин тирән мәгънәне эченә алган төгәл җөмләле халык хикмәте әсәрләре мәкаль дип йөртелә. Мисал өчен: “Эш беткәч, уйнарга ярый”.

Сөйләмне сәнгатьчә бизәү, эмоциональ көчен арттыру максатында күчерелмә мәгънәдә кулланыла һәм синоним сүз белән алыштырып була торган халык иҗаты әсәрләре әйтем дип йөртелә. Мисал өчен: “Кызыл кар яугач”.

2. Түбәндәге мисалларны мәкаль һәм әйтемнәргә аерып языгыз (һәр дөрес җавап 1 балл, барлыгы 4 балл):

– Батыр башлап җибәрә, артыннан мең кул иярә. (**мәкаль**)
– Телеңне теш артында тоту. **(әйтем)**
– Юлыңа ак җәймә.(**әйтем**)
– Туган туфракка баскан эз суынмый.**(мәкаль)**

**2. Әдәбият тарихы.**

1. Үткән уку елында өйрәнгәннәрне искә төшерегез һәм М.Мәһдиевнең “Фронтовиклар” әсәрендәге Рушад образы турында языгыз (10 балл).

**Җавап:** Роман герое Рушад Акбалык мәктәбенә тарих укытучысы итеп җибәрелә. Ул яңарак кына фронттан кайткан. Үзенең Балтыйк диңгезендә хезмәт итүен, сугыш кыенлыкларын, иптәшләрен югалтуларны искә ала. Автор аның беренче тапкыр 6 сыйныфка дәрескә керүен җентекләп сурәтли. Бу сыйныфтагы тәртипсез малайларны җиңәргә, тарих белән кызыксындырырга сабырлыгы, горурлыгы һәм тарих фәнен яратуы ярдәм итә. Вакыйгаларда ул максатчан, тырыш егет итеп сурәтләнә. Уку елы тәмамланганнан соң, институтка читтән торып укырга китеп бара.

2. “Мәҗмугыл-хикәят” (“Хикәяләр җыентыгы”) буенча сорау-биремнәргә җавап бирегез.

1) “Мәҗмугыл-хикәят” кайсы чор әдәби ядкяре?(1 балл)

**Җавап:** Әлеге әсәр XVIII йөз ядкяре.

2) Түбәндәге өзектә урын алган фикерне үз сүзләрегез белән язып аңлатыгыз (4 балл):

“Карт:

– И мәлик (солтан)! Башкалар үстерде – без җимешен ашадык, инде мин үстерәм – башкалар ашасын, – диде.

Бу сүз солтанга ошады:

– Галәмдәге күп эшләр, шуның кебек, бер-берсенә бәйләнешле, мәгънәле сүз әйттең, – дип, картка мең алтын бирде”.

**Җава**п: Карт үзенә кадәр яшәгән кешеләр утырткан агачларның алмасын ашый, шуңа ул үзе дә бакча ясап, агачлар утырта. Аларның җимешен, карт вафатыннан соң, башка кешеләр ашаячак. Аның бу эше һәм сүзләре солтанга бик ошый, чөнки тормышта күп әйбер бер-берсенә бәйле. Мисал өчен, кеше кое казый, ә ул коедан алдагы буыннар да файдаланачак бит.

3) Әлеге хикәятләрдә урын алган солтан образы турында языгыз (5 балл).

**Җавап**: Ике хикәяттә дә солтан гади халык вәкиле булган карт белән аралаша, бу аның кешелекле булуын күрсәтә. Солтан яхшылыкка яхшылык белән җавап бирергә тырыша. Беренче хикәяттә игътибарсызлыгы аркасында картны михнәткә дучар итә. Моның өчен үкенеп, күп акча бирә. Солтан үзе дә тапкыр, шуңа тапкыр һәм тәҗрибәле кешеләрнең хезмәтен дә, әйткән фикерләрен дә бәяли белә.

**3. Әдәби-тарихи характердагы тестларга җавап бирегез (һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә, барлыгы 5 балл)**

1. Татар дәүләт академия театры исемен йөрткән драматург:
а) К.Тинчурин
ә) Г.Исхакый
**б) Г.Камал**
в) Т.Гыйззәт
2. Балалар шагыйре булып танылган әдип:
а) Ә.Фәйзи
ә) Г.Бәширов
**б) Ш.Галиев**
в) Н.Дәүли
3. Г.Тукайның “Милли моңнар” әсәренең жанры:
а) поэма
**ә) шигырь**
б) нәсер
в) мәсәл
4.Түбәндәге авторларны һәм әсәрләрен туры китерегез:
а) Ә.Еники “Матурлык”
ә) Г.Афзал “Мыек борам”
б) Г.Тукай “Су анасы”
в) Г.Ибраһимов “Яз башы”
5. С.Сараиның “Сөһәйл вә Гөлдерсен” әсәре жанры:
а) хикәят
ә) кыйсса
**б) дастан**
в) риваять

**4. Иҗади эш.**

“Атам, анам, җирем, суым,
Дусларым, якыннарым –
Сез минем бетмәс-төкәнмәс
Хәзинәм – алтыннарым”, –

дип яза Фәнис Яруллин. Шагыйрьнең фикерен аңлатып языгыз (10 балл).

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел булараk өйрәнүче укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар**

**(муниципаль этап, 2021-2022 уку елы)**

**8 нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 150 минут сәгать**

**Гомуми балл – 45**

**1. Әдәбият теориясе**.

Мәрсия жанры үзенчәлекләрен М.Акмулланың “Дамелла Шиһабетдин хәзрәт мәрсиясе” әсәренә нигезләнеп аңлатыгыз (10 балл).

**Җавап**: Мәрсия – урта гасырлар әдәбиятының бер жанры. Ул вафат булган кешенең якты истәлегенә атап языла. Андый әсәрләрдә үлгән кешенең матур эш-гамәлләре, якта образы зурлап бәяләнә, башкаларга үрнәк итеп куела.

Акмулланың “Дамелла...” әсәре атаклы дин галиме, мәгърифәтче Ш.Мәрҗани үлеменә бәйле языла. Әсәрдә әлеге шәхеснең күп эш-гамәлләре яктыртыла. Халыкны мәгърифәтле итү эшенә керткән өлеше бәяләнә. Хезмәтләрен югары бәяләп, халыкка хезмәт итүен ача. Ш.Мәрҗанинең якты, олы образы күз алдына бастырыла.

**2. Әдәбият тарихы**.

1. Үткән уку елында өйрәнгәннәрне искә төшерегез һәм М.Мәһдиевнең “Без – 41 ел балалары” әсәреннән бер герой (Зарифуллин яисә Гыйззәтуллин) турында языгыз (10 балл).

**Җавап**: Өзекләрдә сурәтләнгән Зарифуллин – Арча педагогика училищесында укучы Мөрәле авылы малае. Башкалардан әллә ни аерылып тормый: шаяра, еш кына, дәрестә укыйсы килмичә, уен-көлке оештыра. Ярлы гына гаиләдән, аның чалбарының тез башлары һәрвакыт ямаулы. Үзен иркен тотарга гадәтләнгән малай рус теле укытучысының көчен, ныклыгын таный. Ул кушканнарны эшләргә туры киләчәген аңлап, иптәшләре белән бәхәскә катнашмый. Зарифуллин немец теле укытучысын да сынап карый, әмма аның ихтыярына каршы тора алмый, өй эшен өйрәнеп килеп, “5” ле ала.

2. М.Әгъләмовның “Акмулла арбасы” поэмасы буенча сорау-биремнәргә җавап языгыз.

1) Акмулла арбасының нигә өч бүлектән торуын аңлатыгыз (2 балл).

**Җавап**: Акмулланың арбасы өч бүлектән торып, берсендә китаплар, уку кирәк-яраклары сакланган; икенчесендә эш кораллары (өтерге, балта, ышкы һ.б.) булган; өченчесендә үзе утырып йөргән.

2) “Халыкларның йөрәгенә кергән,
Кунак булып түгел, үз булып”, –

дигән юлларга салынган фикерне аңлатыгыз (4 балл).

**Җавап**: Акмулла халыкны мәгърифәтле итәргә теләп шигырьләр язган, үзе балалар да укыткан. Изге гамәлләре белән халык күңелендә урын ала. Автор язганча, читтән килгән кунак булып түгел, бәлки шул халыкның үз кешесе, үз улы булып халыкка танылган.

3) Акмулла – чичән шагыйрь, ягъни аз сүз белән тирән, тапкыр мәгънә белдерү остасы. Шуңа нигезләнеп, түбәндәге мисалларны аңлатыгыз: (һәр дөрес җавап 2 балл, барлыгы 4 балл)

– “Әдәп, дигән – мәхәббәткә сәбәп, дигән...”

**Җавап**: Бу тезмә тирән мәгънә белдерә. Автор кешедәге әдәплелек сыйфатын бик югары бәяли. Андый кешенең башкалар мәхәббәтенә (яратуына, хөрмәтләвенә) лаек булуын искәртә.

– “Галим булса, милләт өчен зарлы булсын..."

**Җавап**: Автор укымышлы, белемле кешенең тормыштагы вазифасын аңлатып үтә. Галим кеше үзенең халкы, милләте өчен борчылып, аңа ярдәм итү теләге белән яшәргә тиеш, дигән фикерне җиткерә.

**3. Әдәби-тарихи характердагы тестларга җавап бирегез** (һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә, барлыгы 5 балл)

1. Татар дәүләт академия театры исемен йөрткән драматург:
а) К.Тинчурин
ә) Г.Исхакый
**б) Г.Камал**
в) Т.Гыйззәт
2. Түбәндәге әсәрләр арасында берсе Г.Тукай шигыре түгел:
а) “Милли моңнар”
ә) “Пар ат”
**б) “Кораб”**
в) “Шүрәле”
3. “Дастаны Бабахан” әсәренең авторы:
**а) Сайади**
ә) Акмулла
б) Т.Ялчыгыл
в) Ф.Кәрими
4. Ф.Кәриминең “Морза кызы Фатыйма” әсәре жанры:
а) нәсер
ә) роман
**б) хикәя**
в) бәет
5. Түбәндәге әсәрләрнең берсен Г.Ибраһимов иҗат иткән:
а) “Йолдызлы малай”
ә) “Кем җырлады”
**б) “Алмачуар”**
в) “Пар ат”

**4. Иҗади эш**.

“Куркакның җаны кала,
Батырның даны кала.
Җан гомере – санаулы,
Дан гомере – дәвамлы”, –

дип яза Фәнис Яруллин. Шагыйрьнең фикерен аңлатып языгыз (10 балл).

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел булараk өйрәнүче укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар**
**(муниципаль этап, 2021-2022 уку елы)**
**9 нчы сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл – 45**

**1. Әдәбият теориясе**.

Мәгърифәтчелек реализмы нәрсә ул? Фикерегезне М.Акъегетзадәнең “Хисаметдин менла” әсәренә нигезләнеп аңлатыгыз (10 балл).

**Җавап:** Чынбарлык күренешләрен, яшәешне мәгърифәт һәм әхлакый кыйммәтләр аша чагылдырган иҗат методын мәгърифәтчелек реализмы дип атыйлар.

М.Акъегетзадәнең “Хисаметдин менла” әсәре әлеге методка нигезләнеп язылган. Анда чынбарлыкта барган вакыйгалар сурәтләнә. Автор үзәккә аң-белем, тәрбия аша кешене һәм җәмгыятьне үзгәртеп була дигән фикерне чыгара. Шуңа да уку, белем алу, гаилә тәрбиясе мәсьәләләренә җитди урын бирелә. Конфликт уңай һәм тискәре геройлар арасында. Ул Хисаметдин һәм дусларының җиңеп чыгуы белән чишелә. Геройлар ачык күренеп торган ике лагерьга бүленгән: уңай һәм тискәре. Мәгърифәтчеләр хатын-кызның җәмгыятьтәге урыны мәсьәләсен дә алга куялар. Әсәрдә Хәнифә укымышлы, белемле, тәрбияле кыз итеп сурәтләнә һ.б.

**2. Әдәбият тарихы.**

1. Үткән уку елында өйрәнгәннәрне искә төшерегез һәм М.Мәһдиевнең “Кеше китә – җыры кала” әсәрендәге Васфикамал турында языгыз (10 балл).

**Җавап**: Әсәрдә Васфикамал усал килен буларак сурәтләнә. Ул авыл хатыны, эшкә уңган, булган, тырыш. Кырда икмәк урганда башкалардан ике тапкыр артык эшли. Әмма Васфикамалның теле бик яман. Ул кешегә турысын әйтә, кайвакыт ни әйткәнен дә уйлап тормый, шуңа да тирә-як күршеләр белән ачуланыша, туганнар да килми башлый. Ямьсез телле булса да, ул явыз түгел, усаллыгы үз хокукын яклау булып чыга. Шуңа да аны ире Хәкимулла ярата.

2. “Идегәй” дастаны белән бәйле сорау-биремнәргә җавап языгыз.

1) Туктамыш хан белән Аксак Тимер арасындагы низагның сәбәбен аңлатыгыз (3 балл).

**Җавап**: Алтын Урда ханы Туктамышның ау лачыны (Төкле Аяк) була. Ул ауга осталыгы белән дан казана һәм хан лачыны дигән исем-дәрәҗә ала. Сәмәрканд шәһәрендә Аксак Тимер идарә итә. Туктамышның үзенә буйсыну билгесе итеп, әлеге ау лачынын бирүне таләп итә. Әмма Туктамыш хан моны кире кага, Аксак Тимергә тупас, хәтта мыскыллап җавап бирә.

2) Идегәй ни өчен Кобогыл исемендә үсә? (3 балл)

**Җавап**: Туктамыш хан лачыннар караучы Котлыкыя бине һәм нәселен үлемгә хөкем итә. Хан киңәшчесе Җантимер, бу нәсел дәвамчысын саклап калу өчен, үз баласын Котлыкыяның бишектәге баласына алыштыра. Шул рәвешле, Котлыкыя нәселе белән бергә, Җантимер баласы да үтерелә. Ә инде Идегәй Җантимернең алыштырылган улы Кобогыл исеме белән үсә.

3) Идегәйгә характеристика бирегез.(4 балл)

**Җавап**: Идегәй кечкенәдән гаять зирәк, үткен, акыллы булып үсә. Әсәрдә мондый сыйфатлары атап үтелә: өч яшендә укырга өйрәнә, зирәклеге белән дан ала, алтыда атка менә, җидедә җәя тарта, унда чүл-кыяларны үтеп чыга, уникедә ир булып таныла, унбиштә үзенең яшьтәшләрен көрәштә егып сала һ.б. Идегәй гадел, ятимнәргә булыша, адашканнарга юл күрсәтә. Шул ук вакытта Туктамыш алдында баш имичә, горурлыгын да күрсәтә. Егетнең осталыгын күреп, Туктамыш хан аны Сарайга – үз янына ала, илне саклау бурычын куя. Идегәй тиз арада сәүдә эшен җайга сала, тәртип урнаштыра, ил казнасын баета һ.б.

**3. Әдәби-тарихи характердагы тестларга җавап бирегез** (һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә, барлыгы 5 балл)

1. Татар дәүләт академия театры исемен йөрткән драматург:

а) К.Тинчурин

ә) Г.Исхакый

**б) Г.Камал**

в) Т.Гыйззәт

2. Бирелгән әсәрләрне язылу вакытына карап урнаштырыгз:

а) XVIII йөз .... (“Мәҗмугыл-хикәят”)

ә) XIX йөз башы .... (Һ.Салихов.”Әдәпләр турында җыентык”)

б) XIX йөз ахыры .... (Акмулла. “Дамелла Шиһабетдин хәзрәт мәрсиясе”).

в) XX йөз башы ... (С.Рәмиев. “Мин”)

3. Түбәндәге авторларны һәм әсәрләрне туры китереп языгыз:

а) Ш.Маннур (“Муса”)

ә) М.Фәйзи (“Галиябану”)

б) М.Мәһдиев (“Кеше китә – җыры кала”)

в) Р.Харис (“Шагыйрь мәхәббәте”)

4. “Идегәй” дастаны герое түгел:

а) Туктамыш хан

ә) Котлыкыя би

б) Җантимер

**в) Таһир**

5. Мәгърифәтчелек чоры әдибе:

а) Кол Гали

**ә) К.Насыйри**

б) С.Сараи

в) Котб

**4. Иҗади эш**.

“Иелгән башларны кылыч кисми,
ләкин аларны һәрбер көчек тешли”, –

дип яза Фәнис Яруллин. Шагыйрьнең фикерен аңлатып языгыз (10 балл).

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен татар әдәбиятыннан олимпиада биремнәренә җаваплар**
**(муниципаль этап, 2021-2022 уку елы)**
**10нчы сыйныф.**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл – 45**

1. **Әдәбият теориясе.**

1) Әдәбият тарихының чор-этапларга бүленешендә нәрсә нигез булып тора? (5 балл)

2) Болгар һәм Алтын Урда чорларын ике дәвер (этап) буларак өйрәнү шартларын күрсәтегез. (5 балл)

**Җавап**: 1) Борынгы чорлардан алып хәзергегә кадәр әдәбият тарихы чор-этаплар аша үсеп-үзгәреп килә. Ул бүленеш шартлы. Аерым авторлар иҗаты берничә чорны үз эченә алырга мөмкин. Әдәбият тарихының чор-этапларга бүленешендә төп ике фактор аерып чыгарыла: 1) иҗтимагый-тарихи шартлар, ягъни җәмгыять үсешендә барлыкка килгән кискен үзгәрешләр. Мисал өчен, Бөек Ватан сугышы башлану, әлеге елларны башкалардан аерып куюга китерә; 2) әдәбият үсеш-үзгәрешендә җитди үзенчәлекләр барлыкка килеп, бер чор әдәбияты икенчесеннән аерылып тора башлый.

2) Болгар һәм Алтын Урда чорлары ике дәвер (этап) булып өйрәнелә. Болгар дәүләте IX–XIII гасырларда яши һәм 1237 елда Батый хан гаскәре тарафыннан яулап алына. Ул Алтын Урда дәүләте составына керә, аның бер өлеше булып китә.

Болгар һәм Алтын Урда чоры әдәбиятлары бер-берсеннән аерылып тора. Болгар чоры ядкярләре безгә аз санда килеп җиткән. Иң кыйммәтлесе – Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре. Шуңа нигезләнеп, бу чор әдәбиятын күзалларга мөмкин: гомумкешелек кыйммәтләренә йөз тоту; кеше шәхесен яшәеш белән тыгыз бәйләнештә сурәтләү; дини эчтәлек белән сугарылу; гадел хөкемдар мәсьәләсе куелу; фольклорга нигезләнү һ.б. Алтын Урда чоры әдәбияты үзенчәлекләре: хикәят, дастан, кыйсса, бәет, газәл, робагый һ.б. жанрлар активлашу; Шәрык әдәбиятлары йогынтысы зур булу; назыйрә алымына нигезләнеп, уртак сюжетларга мөрәҗәгать итү; үзәктә кеше һәм аның бәхете мәсьәләсе тору; төп проблемалар буларак мәхәббәт, шәхес иреге, хөкемдар һәм халык, бердәмлек куелу һ.б.

**2. Әдәбият тарихы.**

1. Үткән уку елында өйрәнгәннәрне искә төшерегез һәм Ш.Хөсәеновның “Әниемнең ак күлмәге” драмасында сурәтләнгән Ана образы турында языгыз. (10 балл)

**Җавап**: Драмада Ананың исеме юк, ул аналарның гомумиләштерелгән образы. 9 бала тәрбияләп үстергән, һәрберсенә белем алырга, тормышта үз урынын табарга ярдәм иткән. Ана милли образ булып ачыла. Татар халкына

хас гореф-гадәтләрне, йолаларны саклап һәм яклап яши. Ул бик тырыш, авыру хәлендә дә барлык балаларын тигез күреп, ярдәм итә. Ана корбанчылык сыйфаты белән ачыла. Балалары өчен барысын да бирергә әзер, үзе авырса да түзә, даруын инвалид улы Инсафка бирә. Ана күңелендә борчу бар, чөнки барлык баласын да әдәпле кеше итеп тәрбияли алмаган. Моны ачыктан-ачык әйтә. Ул Исламга әрнүен яшерми. Анының соңгы васыяте дә балаларының чын Кеше булып калуларын теләү белән бәйле.

2. Мөхәммәдьяр тормышы һәм иҗаты буенча сорау-биремнәргә җавап бирегез.

1) Мөхәммәдьяр тормышы һәм иҗаты кайсы чор әдәбиятына карый? (1 балл)

**Җавап**: Мөхәммәдьяр Казан ханлыгы чорында яшәп иҗат итә.

2) Шагыйрьнең безгә килеп җиткән әсәрләрен атагыз (һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә; барлыгы 3 балл).

**Җавап**: Шагыйрьнең безгә 3 әсәре килеп җиткән: “Төхфәи мәрдан”, “Нуры содур”, “Нәсыйхәт”.

3) Шагыйрь поэмаларына хас уртак сыйфат-билгеләрне күрсәтегез. (3 балл)

Җавап: Мөхәммәдьяр поэмалары әхлакый һәм фәлсәфи эчтәлекле хикәятләрдән тора. Алар Аллаһыны зурлау, мактау белән башлана. Әсәрләрдә гаделлек, игелек, миһербанлык кебек сыйфатлар мактала, үрнәк итеп куела.  Автор хөкемдарның гадел булуы халыкка җиңеллек китерә дип күрсәтә.

4) “Нуры содур” поэмасының “Гаделлек турында” хикәясендә урын алган гаделлек һәм золым турында автор фиккерен аңлатыгыз. (3 балл)

Җавап: Автор гаделлекне гаять кирәкле сыйфат итеп ача. Гаделлек белән идарә ителгән илдә иминлек булыр, халык җиңел яшәр, дигән фикерне яклый. Гаделлек булса, ил-дәүләт төзек булыр, һәрбер эш уң булыр. Ә инде золымлык белән ил һәм халык хәле яман булыр дигән фикерне җиткерә. Шуңа да золымлык кылучыны кяфер дип атый.

**3. Әдәби-тарихи характердагы тестларга җавап бирегез** (һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә, барлыгы 5 балл)

1. Татар дәүләт академия театры исемен йөрткән драматург:

а) К.Тинчурин

ә) Г.Исхакый

**б) Г.Камал**

в) Т.Гыйззәт

2. Гомумтөрки чор әдәбияты дип билгеләнгән вакыт:

а) I – V йөзләр

ә) VI – X йөзләр

**б) VII – XIII йөзләр**

в) X – XIII йөзләр

3. Түбәндәге әсәрләр арасыннан Йосыф Баласагунлы әсәрен билгеләгез:

**а) “Котадгу белек”**

ә) “Диване лөгатет-төрк”

б) “Кыйссаи Йосыф”
в) “Сөһәйл вә Гөлдерсен”
4. Түбәндәге авторларны һәм әсәрләрен туры китереп языгыз:
а) С.Сараи ... (“Гөлстан бит-төрки”)
ә) Котб ... (“Хөсрәү вә Ширин”)
б) Х.Кятиб ... (“Җөмҗөмә солтан”)
в) Харәзми ... (“Мәхәббәтнамә”)
5. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” әсәре герое түгел:
а) Динә
ә) Йагъкуб
б) Ширин
в) Рауил

**4. Иҗади эш.**

“Бу дөньяда һәркемнең үз урыны бар:
Кемдер халыкның күз өстендәге кашы,
Ә кемнәрдер – бәгырендәге ташы”, –
дип яза Фәнис Яруллин. Шагыйрьнең фикерен аңлатып языгыз.(10 балл)

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен татар әдәбиятыннан**

**олимпиада биремнәренә җаваплар**
**(муниципаль этап, 2021-2022 уку елы)**
**11нче сыйныф**

**Башкару вакыты – 180 минут**
**Гомуми балл – 45**

**1. Әдәбият теориясе.**

Әдәби процессның асылын билгеләүче традиция һәм яңачалык (новаторство) нәрсә ул? Фикерләрегезне Бөек Ватан сугышы чоры әдәбиятына нигезләнеп аңлатыгыз. (5б.+5б., барлыгы 10 балл)

**Җавап**: Күптөрле күренешләрне һәм фактларны үз эченә алган әдәбиятның теге яисә бу чордагы хәле, үсеш-үзгәреше әдәби процессс дип атала. Әдәбият үткәннәргә нигезләнеп һәм яңа күренешләр, сыйфатлар белән баеп үсә, үзгәрә. Традиция – үткән чорларның әдәби тәҗрибәсе ул. Язучы шул тәҗрибәне туплау аша иҗатка килә һәм үзе дә аны кемнәргәдер тапшыра. Шул рәвешле аерым сыйфатлар, үзенчәлекләр даими кабатлана, иҗади үзләштерелә. Бөек Ватан сугышы чоры әдәбияты 1941-1945 елларны үз эченә ала. Сугыш шартлары әдәбиятны үзгәртсә дә, ул үткәннән килүче традицияләргә таянып үсә. Әдипләр гуманизм традицияләрен яклап һәм саклап калырга чакыра. Фашизм үзе үлем алып килсә дә, аны немец халкы белән тәңгәлләштермиләр, иң кыен вакытта да кешелеклелекне сакларга чакыралар. Үткән традицияләренә бәйле романтик сурәтлелек үсә, батырлык һәм батырлар күтәрелеп, баетып сурәтләнә. Традицияләргә нисбәтле сурәт чаралары (символ, метафора, эпитет һ.б.) яңа төсмерләргә байый һ.б.

Яңачалык – теге яисә бу чорның үзенчәлекләрен билгеләргә ярдәм иткән яңа күренешләр, билгеле бер әдәби ачышлар ул. Яңалык эчтәлек һәм формада, жанрда, образлар бирелешендә һ.б. булырга мөмкин. Бөек Ватан сугышы чорында әдәбият яңа сыйфат-билгеләр белән байый. Илне яклау, саклау, фашизмга нәфрәт, сугыш авырлыгын күрсәтү, батырлыкка мәдхия уку кебек темалар алгы планга чыга, үзәккә куела. Бу елларда кече жанрлар активлаша – очерк һәм хикәя. Сугыш турында документальлеккә нигезләнгә әсәрләр арта, публицистика активлаша. Бу чорда сугыштагы солдатның яисә тылда калучыларның күңел дөньясын бөтен тирәнлегендә ачу омтылышында психологизм көчәя һ.б.

**2. Әдәбият тарихы.**

1. Үткән уку елында өйрәнгәннәрне искә төшерегез һәм К.Тинчуринның “Сүнгән йолдызлар” пьесасында сурәтләнгән Сәрвәр образы турында языгыз.(10 балл)

**Җавап**: Әсәрдә Сәрвәр ятимә кыз итеп бирелә. Ул Гөлнур әбисе белән яши. Кыз бик матур, тырыш, булдыклы. Аны белгән кешеләр тарафыннан хөрмәт ителә. Сәрвәр Исмәгыйльне ярата һәм аның белән кавышып, бәхетле булу өчен барысын да эшләргә әзер. Автор кызның яратуын сокланып сурәтли. Сәрвәргә ихтыяр көче, максатчанлык хас. Ул үз кулы белән сөйгәненең колагына “дару” сала һәм үлеменә сәбәпче була. Моны бик авыр

кичереп, акылдан яза. Сәрвәр гаять кешелекле. Надирны ярата алмаса да, егетнең хисләрен аңлый, аңа хөрмәт белән карый.

**2. М.Хәсәновның “Язгы аҗаган” романы буенча сорау-биремнәргә җавап языгыз.**

1) Романның төп сюжет сызыкларын күрсәтегез. (2 балл)

**Җавап**: Әсәр үзара бәйләнеп, керешеп киткән өч сюжет сызыгыннан гыйбарәт. Беренчесе – «Яңа нефть ятмаларының перспективасын билгеләү, матди базасын тикшерү, Кама буенда нефть һәм газ чыгару идарәсе төзү мәсьәләсен хәл итәргә дип килгән» комиссия эшенә бәйле. Әлеге комиссия составына өлкә газетасының махсус хәбәрчесе буларак кертелгән Фәйзи башка сюжет сызыкларын тоташтырып, ачыклык кертеп, урыны белән бәя биреп тора. Икенчесе – Газиның гыйбрәтле язмышы һәм өченчесе – Иргали, аның гаилә тормышы тасвирлану.

2) Гази яисә Иргали образларының берсенә характеристика бирегез.(4 балл)

Гази – авылның беренче большевигы Хаҗи улы. Яшьтән акыллы, әдәпле булып, хезмәт яратып үсә. Актив, шактый кыю, ихтыяр көченә ия. Чор идеологиясе, хаксызлык, гаделсезлек йогынтысында куркаклык, көчсезлек күрсәтә һәм шуның өчен үзе дә гомере буе үкенеп яши. Нинди генә авырлыкларга очрамасын, Гази намуслы, кешелекле булып кала. Аның Ватанына һәм сөйгәненә тугрылыгын, рухи газаплар кичергәндә саклап калган сабырлыгын, “кеше” дигән бөек исемгә тап төшерми яшәвен автор сокланып сурәтли. Гази һәрдаим җәмгыятьнең гаделсезлеге белән очраша, үзенең чиста исемен һәр эш-гамәлендә исбатлап яшәргә тиеш була. Бер яктан, үзенең хаклы булуын күрүе, намуслы хезмәт итүе, икенче яктан җәмгыятьтәге гаделсезлек, аңа яраклашудан качуы, Газинең эчке каршылыгын китереп чыгара.

Иргали – авылның урта хәлле крестьяны. Вакыйга-күренешләрдә үзен батыр солдат, ярдәмчел, кешелекле итеп таныта. Ул –чын мәгънәсендә җир хуҗасы. Бар көчен, талантын биреп иген игә, терлек үстерә. Романда Иргали туры сүзле, һәрнәрсәгә крестьянның салкын акылы белән уйлап якын килә торган үзенчәлекле герой булып ачыла. Кешегә эш-гамәленә карап бәя бирә, кем булуын күзенә бәреп әйтә, шуңа да партия исеме артына үшәнлеген, наданлыгын, әдәпсезлеген яшергән, ялтыравыклы сүзләр сөйләп, хезмәт итмичә генә яшәргә омтылучы Халәп белән кискен каршылыкка керә. Иргали кайда гына булмасын, нинди генә эш белән шөгыльләнмәсен, кешеләрне, хезмәтне оештыру сәләтен, нык ихтыярлы, гаҗәеп сабыр, гадел, ярдәмчел булуын күрсәтә. Үз мәнфәгатьләрен читкә куймаган хәлдә, ул милләттәшләре, хезмәттәшләре тормышын да кайгыртып яши. Гаепсезлеге ачыклангач та, кешеләргә кирәклеген аңлап, Себердә кала. Иргали гаделсезлекләргә каршы шактый актив көрәшә, шуңа да тормышта үз урынын табып яши, уңышларга ирешә

3) Роман исеме (“Язгы аҗаган”) нәрсәне аңлата? (4 балл)

Гази яшь вакытта язгы аҗаганны күрә, ә халык сынамышы буенча «язын аҗаган күргән кешене гомере буена ачы язмыш, зур афәтләр,

көтелмәгән газап-михнәтләр, фаҗигале хәлләр эзәрлекләр, тормышы тоташтан бәла-казалы, зар-интизарлы булыр» ди. Бу сынамыш романдагы вакыйга-күренешләргә метафора булып килә, әсәрнең төп идеясен аңларга булыша, шуңа да ул исемгә чыгарылган. Гази һәм аның кебек меңнәрнең ачы язмышы, билгеле инде, табигать күренешенә түгел, бәлки Сталин чорының кешелексез күренешләренә, имансыз идеология тудырган миһербансыз, намуссыз кешеләрнең эш-гамәлләренә бәйле.

**3. Әдәби-тарихи характердагы тестларга җавап бирегез** (һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә, барлыгы 5 балл)

1. Татар дәүләт академия театры исемен йөрткән драматург:
а) К.Тинчурин
ә) Г.Исхакый
**б) Г.Камал**
в) Т.Гыйззәт
2. 1930 елларда репрессиягә дучар булган әдип:
**а) Х.Туфан**
ә) Г.Исхакый
б) Һ.Такташ
в) Ф.Хөсни
3.Түбәндәге әсәрләрне һәм жанрларны туры китерегез:
а) И.Юзеев. “Өчәү чыктык юлга” ... поэма
ә) М.Мәһдиев. “Бәхилләшү” ... повесть
б) Г.Ахунов. “Хәзинә” ... роман
в) Г.Камал. “Бүләк өчен” ... комедия
4. Түбәндәге авторларны һәм әсәрләрне туры китерегез:
а) Һ.Такташ “Мәхәббәт тәүбәсе”
ә) Г.Кутуй “Тапшырылмаган хатлар”
б) Ф.Әмирхан “Шәфигулла агай”
в) М.Фәйзи “Ак калфак”
5.Ф.Хөснинең “Йөзек кашы” әсәренең жанры:
а) роман
**ә) повесть**
б) хикәя
в) новелла

**4. Иҗади эш.**
“Бик биеккә менсәң дә син
Әверелмә болытка:
Болытлардан да югары
Җилләр барын онытма”, –
дип яза Ф. Яруллин. Шагыйрьнең фикерен аңлатып языгыз. (10 балл)